БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«03» 04 2026 ел № 151

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керешүче затның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 510-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керешүче затның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы Нигезләмәне раслау турында» 2015 елның 9 июнендәге 264 номерлы карарына (2020 елның 15 маендагы 179 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. 3 пунктның 3 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

- «Муниципаль учреждение җитәкчеләре тарафыннан - әгәр килешүләрнең гомуми суммасы әлеге затның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә, һәм әлеге килешүләр башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында.».

2. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2015 елның 9 июнендәге 264 карары белән расланган (2020 елның 15 маендагы 179 номерлы үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керешүче затның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан керемнәре,

чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

2.1. 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Муниципаль учреждение җитәкчесе үзе, хатыны (ире) һәм/яки кече яшьтәге балалары тарафыннан мәгълүматларны тапшыру елына кадәрге календарь елы эчендә (алга таба- хисап чоры) җир участогы, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча төзелгән һәрбер килешү буенча, әгәр дә мондый килешүләрнең гомуми суммасы хисап чорыннан алдагы соңгы өч ел эчендәге әлеге затның, аның хатынының (ире) һәм кече яшьтәге балаларының гомуми кеременнән артып китсә, шулай ук бу килешүләрне төзү өчен кулланылган акча чыганаклары турында мәгълүмат тапшыра.»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А. Ф. Хәйретдинов